**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Якты Күл авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында**
**2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**19.11.2025 ел.** **№ 1**

«Хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2026 елда үзара салымны 600 сумм күләмендә билгеләргә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Фардеев, Ак.Акатьев, Ленин, Яшел, Ак.Гортышов, Тимер юл, Вахитов урамнары вак таш, асфальт-бетон өслек кулланып юлны ремонтлау);

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зиратны төзекләндерү).

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Якты Күл авыл җирлеге Уставының 69 ст. 5п.) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлеге башлыгы З. З. Мөхтәров